**Татарстан Республикасы**
**Дәүләт Советы Президиумы**

# КАРАРЫ

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында” 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында” 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта “хисап чорыннан соң килүче айның 5 нче числосына кадәр” сүзләрен “хисап чорының соңгы аеның 25 нче числосына кадәр” сүзләренә алмаштырырга;

2) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2011 елның 21 апрелендәге
1560-IV ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумы
карарына кушымта

20___ елның ____яртыеллыгы өчен
___________ сайлау округындагы эше турында
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты
МӘГЪЛҮМАТЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышлары эшендә катнашу | |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Сайлаучылар белән очрашулар, округтагы башка чаралар (җыелышлар, митинглар, пикетлар, конференцияләр, "түгәрәк өстәлләр" һ.б.) | |
| 3. | Гражданнарны кабул итү даталары | |
| 4. | Кабул ителгән гражданнар саны, шул исәптән түбәндәге категорияләр буенча: | |
| | – Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм анда катнашучылар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары | |
| | – Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары | |
| | – тыл хезмәтчәннәре, хезмәт ветераннары, пенсионерлар | |
| | – инвалидлар, инвалид балалар | |
| | – ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар | |
| | – күп балалы гаиләләр | |
| | – яшь гаиләләр | |
| | – эшсезләр һәм вакытлыча эшләмәүчеләр | |
| 5. | Каралган мөрәҗәгатьләр саны, шул исәптән түбәндәге мәсьәләләр буенча: | |
| | – дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге | |
| | – икътисад, сәнәгать | |
| | – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек | |
| | – транспорт һәм юл хуҗалыгы | |
| | – төзелеш, архитектура һәм торак шартларын яхшырту | |
| | – коммуналь хезмәт күрсәтүләр | |
| | – экология һәм табигый ресурслар | |
| | – мәгариф, фән һәм мәдәният | |
| | – сәламәтлек саклау | |
| | – хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау | |
| | – законлылыкны һәм хокук тәртибен саклауны тәэмин итү | |
| | – башка мәсьәләләр | |
| 6. | Гражданнарга уңай җавап бирелгән мөрәҗәгатьләр саны | |
| 7. | Гражданнарның аңлатмалар бирелгән мөрәҗәгатьләре саны | |
| 8. | Гражданнарның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы адресына тәкъдимнәре (шул исәптән законнарны камилләштерү буенча) | |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Гражданнарның Татарстан Республикасы Президенты, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләр җитәкчеләре адресына тәкъдимнәре | |
| 10. | Гражданнарның башка мөрәҗәгатьләре (шул исәптән вазыйфаи затларның гамәлләренә, гамәл кылмавына шикаятьләр) | |
| 11. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә җибәрелгән депутат мөрәҗәгатьләре саны | |

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты имза Ф.И.А.ис.

Дата”.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2014 елның 14 апреле
№ 3473-IV ДС